РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ГЛАВА БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большой Шинар, ул.Кооперативная,36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
06.08.2018

КАРАР
№ 5-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү проекты буенча халык алдында тыңлаулар
игълан итү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.11.2003 ел №131-ФЗ, "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 19 нчы статьясына һәм "Олы Шыңар авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар турында нигезләмә"гә таянып,

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карар проекты буенча халык алдында тыңлауларны кушымтага туры китереп билгеләргә.
2. Билгеләргә:
2.1. халык алдында тыңлауларның көне һәм сәгате: 2018 елның 6 нчы сентябре, сәг.9.00;
2.2. халык алдында тыңлауларның дәвамлылыгы – карар проекты басылып чыкканнан алып халык алдында тыңлауларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә басылган көнгә кадәр 30 көннән дә артык түгел;
2.3. үткәрү урыны: Кече Шыңар мәдәният йорты, адресы: РТ, Саба муниципаль районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 37;
2.4. Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, шулай ук халык алдында тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен сорау язуы түбәндәге адрес буенча бирелә ала: Саба муниципаль районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36; (эш көннәрендә 8.00-16.30 сәг.)
2.5. халык алдында тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен сорау язуы бирү срогы -05.09.2018 кадәр.
3. Авыл җирлеге сәркатибенә:
- халык алдында тыңлауларга әзерлекне, гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алу, халык алдында тыңлауларны уздыруны тәэмин итәргә;
- халык алдында тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ruһәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга;
- әлеге карарны авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты белән бергә "Интернет"мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә

http://pravo.tatarstan.ruһәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

4. Әлеге карарны рәсми басылып чыккан көннән үз көченә кергән дип исәпләргә.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов